
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы
# Мәктәп пульсы



## С 8 мартом!

№7
Март, 2025 г.




Дорогие наши учителя и ученицы, поздравляем вас с праздником весны, с 8 Марта! Желаем огромного счастья, личных побед, благополучия, процветания! Будьте всегда такими же очаровательными, жизнерадостными, озаряйте нас своим светом, лучезарностью и теплом. Больше улыбок и ярких эмоций! Никогда ни в чём не нуждайтесь, с легкостью одолевайте все преграды. Пусть ваше обаяние затмевает солнце и луну, взгляд искрится от любви, а этот весенний праздник подарит неповторимые ощущения. Будьте всегда самыми красивыми и неповторимыми. Новых побед вам и достижений!

Хөрмәтле укытучыларыбыз һәм укучыларыбыз, сезне яз бәйрәме, 8 Март белән котлыйбыз! Зур бәхет, шәхси җиңүләр, иминлек телибез! Һәрвакыт шундый сөйкемле, шат күңелле булыгыз. Елмаюыгызны якыннарыгызга ешрак бүләк итегез. Сезне бары тик якты хисләр чорнап алсын! Беркайчан да күңелегез боекмасын, барлык киртәләрне җиңел үтегез. Сезгә кояштай озын гомер, нык сәламәтлек, гаилә бәхете, эшегездә уңышлар телибез. Бу язгы бәйрәм кабатланмас мизгелләр бүләк итсен. Якыннарыгыз һәрчак янәшәгездә булсыннар! Без сезне хөрмәт итәбез һәм яратабыз!

**В этом выпуске:**


| | |
|---|---|
| Без һәрвакыт истә тотачакбыз | 2 |
| Научно-практический семинар | 3 |
| Сабантуйда уйнала торган милли спорт уеннары | 4 |
| Из школьной жизни... | 5 |
| Страница юного поэта | 6 |
| Тәмле тамак | 6 |

# Без һәрвакыт истә тотачакбыз ...

Бөек Ватан сугышының тынганына сиксэн ел вакыт үтте. Без сугыш чорын күрмәдек. Бу канкойгыч сугыш турында ишетеп кенә беләбез. Сугыш дип әйтүгә, минем күз алдыма җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, ятим балалар килеп баса. Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт китерә. Ять-яшь егетләр, кызлар, туган җирләрен саклау өчен, фронтка китәләр. Тылда калганнар да солдатлар өчен җылы оекбашлар, бияләйләр бәйлиләр. Җиңү өчен дип, бар тырышлыкларын куялар. Сугыш бик күп гаиләләргә кайгы, ачы күз яшьләре китерә. Я ире, я уллары, я әтиләре Ватан өчен яу кырларында мәңгегә ятып кала. Ачлыктан тилмереп үлүчеләр дә күп була сугыш елларында. Шулай ук фашист концлагерьларында һәлак булучыларның саны да исәпсез. Бу сугышта бик күп якташларыбыз корбан булган. Нинди зур югалтулар!

Ләкин халыкның тырышлыгы бушка китми: күптән көтелгән Җиңү көне килә. Бу көн халкыбыз күңелендә мәңге онытылмас көн булып уелып кала. Хәзерге вакытта да 9 нчы Май Җиңү көне буларак билгеләп үтелә.

Менә 80 ел инде тыныч хезмәт фронтында эш кайный. Ләкин сугыш китергән тирән хәсрәт, яралар һаман да үзен сиздерә. Ветераннарның күкрәгендә кыймылдаган мина кыйпылчыгы аша, әти сүзен әйтергә тилмереп үскән сабыйлар аша, ничә еллар буена олы юлдан күзен алмый газиз балаларын көткән аналар аша, әле һаман бер-берсен эзләүче фронтовик- дуслар аша…

Сугышның афәтен, авырлыкларын миңа сөйләгән, безгә кадерле кеше булган бабаем турында язмасам гөнаһ булыр иде.

Гайнетдинов Галимҗан Гайнетдин улы Татарстан Республикасы Арча районы Югары Бирәзә авылында өченче бала булып гади крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе - Гайнетдинов Гайнетдин белән Галимә гаиләсендә дөньяга килгән 4 бала арасында үскән Галимҗан абыйлары апаларыннан эшкә өйрәнеп, үскән егет булып, кул арасына бик тиз керә.

Башлангыч белемне Югары Бирәзә башлангыч мәктәбендә ала, аннан, Өчиле җидееллык мәктәбендә укый.

1937 нче елда советлар армиясенә чакырыла, анда 3 ел хезмәт итә. Бөек Ватан сугышы башлангачта фронтка алына, Ленинград оборонасында катнаша.Шул бәрелеш вакытында каты җәрәхәтләнеп пленга эләгә.1945нче елда совет солдатлары аны пленнан коткаралар.

Туган авылы Югары Бирәзәгә 1946 нчы елда кайта.1947 нче елда Шакирова Гайшә Шакир кызына өйләнеп гаилә корып җибәрәләр,кызлары туа.Матур гаилә булып тынычлап яшәргә ирек бирмиләр Галимҗан бабайга. Аны сугышта булмадың диеп 1949 нчы елда Себергә сөргенгә куалар.Ул аннан 1956 нчы елда гына кабат туган ягына гаилэсе янына кайтып урнаша.Аннан аларның 3 балалары туа.

Туган авылыны кайткач Галимҗан бабай торле эшләрдә эшли. Колхозда бригадир булып, тракторист булыпта эшли.

Гайнетдинов Галимҗан Гайнетдин улы түбәндәге бүләкләргә ия була:

1. «Германияне җиңгән өчен һәм Совет Армиясенә һәм Флотына 30 ел» медале
2. «Мактау билгесе» ордены
3. 41-45 елларда Бөек Җиңүнең 50 еллыгы уңаеннан ТР истәлекле билгесе.
4. «1941-1945 еллар сугышы елларында фидакарь хезмәт өчен» медале
5. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены.

Күпме еллар узса да, халык хәтерендә Бөек Ватан сугышы иң авыр, иң дәһшәтле сугыш буларак сакланыр, һәм халкыбызның кылган батырлыклары һәрвакыт хөрмәт һәм соклану белән искә алыныр.












***Мәликә** Җәләева, 9 А нче сыйныф укучысы.*

# Научно-практический семинар


11 марта в нашей школе прошёл научно-практический семинар «Развитие познавательной активности на предметах естественно-научного цикла». Для гостей из Смак-Корсинской школы и Арской школы №7 были организованы мастер-классы по биологии, химии, физике и робототехнике с использованием оборудования «Точки роста».

В ходе семинара участники ознакомились с деятельностью центра в нашей школе, с возможностями, пришедшими к нам с данным проектом. Ученики смогли сами попробовать поработать с лабораторным оборудованием. Мероприятие прошло увлекательно и познавательно, каждый узнал для себя много нового. Надеемся, что полученный на семинаре опыт поможет ребятам в их учебной деятельности, а особенно при сдаче государственных экзаменов.











# Сабантуйда уйнала торган милли спорт уеннары

Сабантуй бәйрәме җыр, бию белән башланып китә. Башта кыр батырларын, алдынгыларны хөрмәтләп бүләкләр, рәхмәт хатлары тапшырыла. Аннары мәйданга яллары төрле төстәге тасмалар белән үрелгән, арбалары чигүле сөлгеләр белән бизәлгән атлар керә. Арбада утырган егет-кызлар гармунга җыр суза. Алар барысы да татар милли киемнәреннән. Ләкин атлар инде күп авылларда бетеп барганлыктан, бизәлгән атларга утырып мәйдан тирәли әйләнү гадәте дә күп авылларда бетеп бара. Шулай ук бәйрәмгә кадәр бер атна алдан бүләк җыю күренеше дә, бизәлгән атларга утырып, гармун тартып, җыр-бию белән оештырыла.

Бәйрәм төрле милли спорт ярышлары, кызыклы уеннар, концерт белән үрелеп бара. Бу уеннар мәйданның төрле урыннарында үткәрелә. Спорт уеннарыннан түбәндәгеләрне әйтеп китәргә кирәк: авыр әйберләр күтәрү- таш, герләр, бүрәнә; кул көрәше; капчык киеп сикерү; аркан тарту; таяк тарту; уктан ату; колгага менү; авыш баганага менү; колгада капчык сугышы, кашыкка йомырка салып йөгерү, чүлмәк вату һәм башка бик күп кызыклы ярышлар оештырыла. Өлкәннәр өчен дә, кечкенәләр өчен дә аерым уеннар уздырыла. Мин дә мондый уеннарда теләп катнашам. Бигрәк тә йөгерешчеләр өчен булганын көтеп алам.

Ат - Сабантуйда төп фигураларның берсе. Сабантуйда тамашачы ат ярышын бик кызыксынып караган. Алда язып үткәнемчә, хәзер күп кенә авылларда ат көчен тимер транспортлар алыштырды. Шуңа күрә авылларда атлар асрау кимеде. Сабантуй бәйрәмнәрендә ат ярышы зур район, шәһәрләрдә генә оештырыла башлады. Ат ярышы мәйданнан читтәрәк була. Ярышка атларны күрше-тирә районнардан да алып киләләр. Җиңгән атларга бүләкләрне атның ялына бәйлиләр. Сабантуйда иң соңгы килгән ат муенына авыл киленнәре чиккән сөлгеләрен бәйли торган булганнар. Бу оттырган җайдакның күңелен күрү һәм атны юату өчен эшләнгән.

Ә атлары булмаган кечерәк авылларда ат ярышын малайлар чабышы алыштыра. Ул ярыш та мәйданнан читтәрәк - кырда оештырыла. Иң беренче килгән 3 малайга кыйммәтле бүләкләр тапшырыла. Шулай ук иң соңгы килүче оттырган малайны да күңелен күрер өчен бүләклиләр.

Сабантуйда тагы бер кызыклы спорт ярышы: озын колгага менү. Элек мәйдан уртасына куелган озын колганың очына чигелгән сөлге белән читек эленгән. Теләге булган җитез егетләр, шул колгага менеп, я сөлгене, я читекне алып төшәргә тиеш булалар. Хәзер инде читек урынына колга башына читлеккә әтәчне ябып куялар. Батыр егетләр шул шома колгага үрмәләп әтәчне читлектән азат итергә тиешләр. Кем дә кем әтәчне читлекне ачып чыгара - әтәч шуңа була. Шулай ук кыйбатлы бүләк белән дә бүләкләнә. Чөнки шома колгага менү бик күп көч, тырышлык таләп итә.

Аркан тарту - Сабантуйның кызыклы бер спорт уены. Бу төр ярышта кешеләр төркемләп кенә катнаша, урыннар да төркемнәргә бирелә. Һәр төркемдә тигез санда уенчылар. Төркемнәр бер-бер артлы тезелешеп, йөзләре белән уртага карап басалар. Арканны сыбызгы кычкыртылгач тарта башлыйлар. Бер төркем икенчесен билгеләнгән сызык аркылы тартып чыгарырга тиеш була. Җиңүче итеп көндәшләрен тартып җыгарган төркем атала.

Кул көрәше, гер күтәрү, таяк тарту - Сабантуендагы кызыклы спорт төрләре. Монда ир-атлар үзләренең кул көчләрен сыныйлар. Кул көрәшендә хатын-кызлар да катнаша.

Сабантуйда шулай ук җитезлек буенча да ярышалар: кашыкка йомырка салып йөгерү, көянтә белән су ташу, күзне бәйләп чүлмәк вату, күз бәйләп әйбер кисү, катыктан авыз белән акча эзләү һәм башка бик күп кызыклы уеннар уйнала. Мәйданда бәйрәм иртәдән кичкә кадәр дәвам итә.

Бар уеннар уйналып беткәч, Сабантуйның төп батырын билгеләү өчен мәйданга көрәшчеләрне чакыралар. Халык тагы да кызыксыну белән мәйдан тирәли җыела. Һәркем мәйданның төп батырын күреп калырга тели. Татарларның яраткан спорт төре милли көрәш башланып китә. Көрәш – кешенең батырлыгын, яшәү көчен, сугышчанлыгын, җитезлеген сыный торган, күпгасырлык тарихы булган үзенчәлекле спорт төре. Аның мөһим үзенчәлеге: көрәшчеләр билбау яки сөлге тотып бил алыша, ягъни ярышчы көндәшенең билен сөлге белән уратып ала да, шул рәвешле аны җиргә аудармакчы була. Аны сабантуйларда гади генә «бил алышу» дип атасалар да, көрәшсез бер генә сабантуй да уздырылмый. Милли көрәш бәйрәмнең иң кызык өлеше булып тора. Көрәш үсмерләр арасында да оештырыла. Берничә көндәшен җиңгән көрәшче төп батыр исеме ала. Ул традицион бүләк – тәкә һәм кыйбатлы бүләк (машина яисә бүтән кыйбатлы йорт җиһазы) белән бүләкләнә. Кәкре мөгезле тәкә күп кенә халыкларда борынгы заманнардан бирле уңыш, бәрәкәтлелек, муллык, иминлек символы булган. Аның мөгезләре төрки халыкларда кояш белән язны символлаштырган һәм йортны төрле яманлыклардан һәм хәсрәтләрдән саклый дип саналган. Сабантуй батыры - баш батыр легендар сугышчыларның, халык башлыкларының һәм каһарман ханнарның варисы буларак кабул ителгән. Ел буена Сабантуй батырының исеме телдән төшми.

*__Әмир__ Гыйлфанов, 9 нчы сыйныф укучысы*

# Из школьной жизни...

6 марта наставники из 7Б класса провели у своих подшефных 2Б класса конкурсно – игровую программу «23 + 8», посвящённую Дню защитника Отечества и Международному женскому дню. Во время мероприятия ребята разделились на 2 команды: «23 февраля» и «8 марта». Дети отвечали на весёлые шуточные вопросы, соревновались в отгадывании животных, девочки показали свои знания в приготовлении каши, а мальчики в умении складывать самолетики. Команда девочек и мальчиков успешно прошли все испытания. В итоге победила дружба. А в конце были поздравления в стихах от девочек мальчикам, и девочкам от мальчиков, ну и, конечно же, маленькие подарки. От мероприятия все получили радостные эмоции и море позитива.




В рамках Международного женского дня для обучающихся 6А класса состоялся мастер-класс по изготовлению можжевеловой рамки для семейных фотографий. Нетрадиционная техника выполнения очень увлекла наших ребят. Они с большим увлечением принялись к изготовлению изделия, в качестве подарка для своих мам, бабушек и сестёр. Мастер-класс проходил в теплой, дружеской обстановке.




В Арском районном Доме культуры организована республиканская передвижная фотовыставка, на которой представлены портреты отцов участников специальной военной операции со всех районов Республики Татарстан. 12 для учеников нашей школы была организована обзорная экскурсия по выставке "Отец Героя". Дети с большим вниманием слушали рассказ экскурсовода, задавали интересующие вопросы и с особым трепетом рассматривали фотографии военнослужащих и их отцов. Наша школа также приняла активное участие в организации данного мероприятия





13 марта - учащиеся 5 “А” класса АСОШ №2 познакомились с жизнью и творчеством русского писателя, драматурга – Антона Павловича Чехова. Наша встреча была посвящена к юбилейной дате – 165-летию со дня рождения писателя. Его произведения до сих пор остаются актуальными для разных поколений. Ребята познакомились с творчеством писателя, узнали самые интригующие факты из жизни Чехова.



# Страница юного поэта...

**Пока они с нами**

Как часто мы не замечаем
Морщинки на родном лице,
И редко маму навещаем,
Всё занятые в суете.

А время птицей пролетает,
Не остановишь, не вернёшь.
И седина лишь прибывает,
А ты всё занят и не ждёшь.

Звони почаще, будь внимательней,
Дари улыбку и тепло.
Пусть будет каждый день старательно
Согрет заботой и добром.

Не откладывай на завтра
Тёплых слов и нежных чувств.
Жизнь порой бывает кратка,
Не копи на сердце грусть.

Цени моменты встреч бесценных,
Храни их в памяти своей.
Нет в мире глаз таких бесценных,
Как добрый взгляд родных очей.

**Скажи спасибо ей**

Пока есть время, не молчи,
Скажи "спасибо" ей в ночи,
За все бессонные часы,
За седину её красы.

За колыбельные слова,
За то, что ты живёшь сполна,
За каждый трепетный совет,
За тёплый утренний привет.

За нежность ласковых речей,
За блеск встревоженных очей,
За то, что верит и простит,
Когда весь мир не устоит.

За силу любящей души,
За годы, прожитые в тиши,
За то, что сердцем всё поймёт,
За то, что вечно тебя ждёт.

Цени, люби, благодари,
От всей души ей говори,
Как дорога она тебе,
Как благодарен ты судьбе.

***Эльвира** Насифуллина, 7А класс.*

# Тәмле тамак

Өчпочмак пешерү өчен кирәкле ингредиетлар: әче камыр – 55 г. Эчлек өчен: ит – 30 г, бәрәңге – 30 г, башлы суган – 10 г, сар май – 5 г, тәменчә тоз, борыч.

Эш барышы: итнең сөяксез җирен һәм бәрәңгене шакмаклап турыйбыз. Бәрәңге каралмасын өчен, аны салкын суда тотабыз, тишекле чүмечтә саркытабыз. Тирән эчле савытка ит белән бәрәңгене салып, вак итеп туралган суган, май, тоз, борыч өстәп, барысын бергә яхшылап болгатабыз.

Камырны тигез кисәкләргә бүлеп, шарчыклар әвәлибез дә чынаяк тәлинкәсе зурлыгында җәябез. Җәймәләр өстенә әзер эчлекне салабыз һәм камырны, кырыйларын өч яктан күтәреп, өчпочмак фрмасына кертеп тоташтырабыз, ачылып китмәсен өчен бөреп куябыз. Өчпочмакны, майланган калайга яисә табага тезеп, мичтә якынча 1 сәгать пешерәбез.

***Мәлика** Җәләева, 9А классы*

***Редактор*** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Гузелия Фаттахова
***Фотокорреспондент*** Илюза Шамсемухаметова
***Корректор*** Гузелия Фаттахова
***Редколлегия*** Камилла Мифтахова

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15
***Сайт школы:*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2